М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов

# Туган тел
## (ТАТАР ТЕЛЕ)

### 1 сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

*Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен*
*(татар телен туган тел буларак*
*өйрәнүче укучылар өчен)*

КАЗАН
2020

УДК 811.512.145 (075.2)
ББК 81.632.3я71
Ш92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

**Шәкүрова, М. М.**

Ш92 Туган тел (татар теле). 1 сыйныф. Методик әсбап : башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. — Казан, 2020. — 79 б.

Методик әсбапта 1 сыйныфта программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр, программа материалының эчтәлеге бирелә, дәреслек белән эшләү тәртибе аңлатыла, дәрес үрнәкләре бирелә. Тематик планда ике юнәлеш өчен булган лексик, грамматик материал, укучыларның эшчәнлек төрләре, укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә куелган таләпләр карала.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Г. Ибрагимов исем. ТӘһСИ, 2020
© М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов, 2019

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 1 сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК үз эченә уку әсбабы, электрон дәреслек, укучы өчен эш дәфтәре, аудиоязмалар дискы һәм укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китереп укытыла. Туган тел (татар теле) предметыннан белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга, язарга, фикерләргә өйрәтү таләп ителә.

1 сыйныфта «Туган тел (татар теле)» предметын укыту түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлтелә:

- укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру. Сөйләм мөмкинлекләреннән чыгып, телдән һәм язмача аралашырга өйрәтү;
- балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләре аша, тел гыйлеме бүлекләрен сөйләмиятнең нигезенә салып өйрәтү.

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар:

- Татарстан Республикасында төрле милләтләр өчен аралашу чарасы буларак, татар теле турында мәгълүмат бирү;
- сөйләмә һәм язма телне үстерү максаты белән телнең грамматик нигезләрен ачыклау;
- тел материалын үзләштерү барышында, аралашу очракларында, рольле уеннарда укучының шәхси сыйфатларын, игътибарын, фикерләү сәләтен, хәтерен һәм иҗадилыгын үстерүгә юнәлеш бирү;
- предметка карата кызыксыну, уңай мотивация, туган телне өйрәнүгә мөмкинлек бирә торган махсус универсаль уку гамәлләре формалаштыруга йөз тоту.

# ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮДӘ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

## Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре

➥ туган телгә, туган иле — Россия Федерациясе һәм туган җире — Татарстан Республикасына мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләрен тәрбияләү;

➥ татар теленең халкыбыз өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуына төшенү;

➥ үз-үзеңне тотуның билгеләнгән нормаларын үтәү, үз гамәлләреңдә уңай мисалга таяну сыйфатларын үстерү;

➥ үзен тыныч, итагатьле итеп тота белү, әңгәмәдәшен ихтирам белән тыңлау;

➥ иҗади активлык һәм фикерләү сәләтен үзлектән үстерүгә әзерләү.

***Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:***

➥ *укуга, хезмәткә карата җаваплы мөнәсәбәт тәрбияләү;*

➥ *башка кешегә, аның фикеренә, дөнья һәм Россия халыкларының тарихына, гореф-гадәтләренә, телләренә аңлы, ихтирамлы һәм игелекле мөнәсәбәт формалаштыру;*

➥ *үз-үзеңне тәртипле тоту кагыйдәләрен өйрәнү.*

## Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

**Укытуда предметара бәйләнеш:**

➥ татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау һәм шул телдә фикерли белү, иркен сөйләшү;

➥ татар телен әдәбият белән бәйләп, матур әдәбият әсәрләрендәге тел чараларының тәэсир көчен, сәнгатьлелек булдырудагы ролен аңлау;

➥ телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык хисен тәрбияләү.

Туган тел (татар теле) укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль

уку гамәлләрен ***(танып белү, регулятив, коммуникатив универсаль уку гамәлләре)*** формалаштыруга хезмәт итә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- белем алу максатын һәм бурычларын мөстәкыйль билгеләү, танып белү мотивларын һәм кызыксынучанлыкны үстерү;
- яшьтәшләр һәм укытучылар белән уку эшчәнлеген оештыра, төркемдә һәм үзлектән эшли, үз фикереңне формалаштыра, аргументлаштыра һәм аны яклый белү.

***Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:***

- *эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыру;*
- *укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлау, анализлау;*
- *дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.*

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

Гомумуку универсаль уку гамәлләре:

- кирәкле мәгълүматны эзләп табу, компьютер чараларын куллану;
- уй-фикерне сөйләмә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештыру.

Логик универсаль уку гамәлләре:

- анализ — төп һәм мөһим булмаган билгеләрен аерып алу өчен, объектны тикшерү;
- синтез — аерым кисәкләрдән бер бөтен төзү, кирәк булганда, җитмәгән компонентлар өстәү.

Проблема кую һәм аны чишү:

- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- иҗатка һәм эзләнүгә корылган проблемаларның чишелеш алымнарын мөстәкыйль табу.

***Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:***

- *фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;*
- *төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;*

- *тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- уку барышында укытучы һәм яшьтәшләре белән хезмәттәшлекне планлаштыру — максатны, уку процессында катнашучыларның вазифаларын, үзара бер-берсенә тәэсир итүләрен билгеләү;
- сораулар кую — мәгълүматны эзләү, туплауда хезмәттәшлек;
- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек итеп җавап бирә белү;
- үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә алу;
- фәннәрне үзләштерү барышында, фәнни-эзләнү, иҗади һәм башка эшчәнлек вакытында, шулай ук аралашу процессында (укучы — укучы, укучы — укытучы һ.б.) коммуникатив компетентлыкны камилләштерү.

***Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:***

- *аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);*
- *парларда һәм күмәк эшли белү;*
- *мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;*
- *әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;*
- *төрле тормыш ситуациясенә һәм геройларның гамәлләренә бәйле сөйләмне куллана һәм бәя бирә белү.*

## Предмет буенча нәтиҗәләр

- коммуникатив бурычны уңышлы хәл итү өчен, сөйләмиятнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерү: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңлау; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белү; сөйләм этикеты нормаларын саклап, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү;
- лингвистик компетенция формалаштыру өчен, тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерү: тел белеме һәм аның төп

бүлекләре; тел һәм сөйләм, телдән һәм язма сөйләм; аралашу ситуациясе; монолог, диалог һәм аларның төрләре;

➥ этномәдәни компетенция формалаштыру максатыннан, укучыларга телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуын аңлату, тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәтү.

***Укучы түбәндәгеләрне өйрәнү мөмкинлеген ала:***

➥ *телнең әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыру; татар сөйләм этикеты нормаларын өйрәнү.*

## ПРОГРАММА МАТЕРИАЛЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

«Туган тел (татар теле)» предметының уку материалы сөйләм эшчәнлеге төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) һәм тел белеме бүлекләре буенча төзелгән.

### Сөйләү.

Өйрәнелгән сөйләм берәмлекләрен сөйләм ситуацияләрендә файдалану. Ана теленең орфоэпик һәм интонация нормаларын саклап, диалоглар һәм монологлар төзү, фикерне җиткерү, сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану. Ишеткән текстның эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү.

### Тыңлап аңлау.

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү. Әдәби әсәрләрдән өзекләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге ярдәмендә фикереңне әйтә, аралаша белү. Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

### Уку.

Орфоэпия нормаларын саклап, логик басымны билгеләп уку. Текстның темасын һәм төп фикерен аңлата белү. Таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба алу.

Сыйныфтан тыш уку дәресләрен оештыру, туган телдә китап укырга гадәтләндерү.

### Язу.

Иҗекләрне, сүзләрне һәм җөмләләрне язу күнекмәләрен булдыру. Рәсем ярдәмендә текст төзү. Сүзлекләр белән эшләү. Тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп язу.

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

Дәреслек белән эшли башлаганчы, шартлы билгеләрне карау, укучыларны алар белән таныштыру кирәк.

### Шартлы билгеләр белән танышу



— *текстны тыңла һәм биремне үтә.* Тыңлау өчен тәкъдим ителгән текстлар дискка тупланды. Һәр дәрес өчен аерым аудиоязма бар. Бу эш төре дәреснең 2–5 минутын ала. Укучылар укытучының тавышына, тизлегенә генә өйрәнергә тиеш түгел. Балалар бер-берсенең һәм башка кешеләрнең сөйләмен дә аңлап эш итәргә өйрәнәләр;



— *база өлешен һәм тирәнтен өйрәнүчеләр өчен кагыйдә.* Дәреслек ике юнәлешне берләштереп төзелде. Әлеге тамга белән билгеләнгән теоретик материалны барлык укучылар да өйрәнә. Ул һәр ике программаның мәҗбүри өлешенә кергән;



— *тирәнтен өйрәнүчеләр өчен өстәмә материал.* Куян кучтәнәче, ягъни тирәнтен өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә торган теоретик материалның күрсәткече. Аңы база өлешен өйрәнүче көчле укучылар белән эшләгәндә дә файдаланып була;



— *тирәнтен өйрәнүчеләр өчен күнегүләр.* Дәрестә өйрәнгән яңа теоретик материал төрле биремнәр, күнегүләр, кызыклы эш төрләре белән ныгытыла;



— *парлап эшлә.* Парларда эш ике юнәлеш өчен дә аерым тәкъдим ителә. Алар өйрәнелә торган лексик һәм грамматик материалны үз эченә алган диалог үрнәкләреннән гыйбарәт;



— *сораулар һәм биремнәр.* Текст белән эшләгәндә, сораулар һәм биремнәр ярдәмендә аның эчтәлеге буенча эш алып барыла. Әлеге эш төрен башкарганда, әдәби уку дәресендә өйрәнгәннәр дә күпмедер дәрәҗәдә искә төшерелә. Шул рәвешле, предметара бәйләнеш формалаштырыла.

## Ярдәмче геройлар белән танышу

Дәреслек белән эшли башлар алдыннан, укучыларның игътибарын 4–5 битләргә җәлеп итәргә кирәк. Бу өлештә укытучының «ярдәмчеләре» белән танышабыз. Әлеге материал укучыларга кызыклы формада — театральләштереп тәкъдим ителсә, бик отышлы булыр иде. Укытучы геройлар итеп киендереп, дәрестә өлкән сыйныф укучыларын да катнаштыра ала. Соңыннан түбәндәге тәртиптә укучылар геройларны үзләре белән таныштыралар.

*Укытучы:*

— Исәнмесез! Мин укытучы. Минем исемем — ______________________________.

*Беренче укучы:*

— Исәнмесез, мин _________________.

*Икенче укучы:*

— Исәнме! Минем исемем — ______________________________ .

*Өченче укучы:*

— Хәерле иртә, ә мин _________________ . Син кем?

*Дүртенче укучы:*

— ______________________________ ...

Сыйныфтагы барлык укучы да үзе белән таныштырып чыга.

## Уку әсбабының структурасы

Уку әсбабы ике зур теманы үз эченә ала. Ул темалар 12 кечкенә темага бүленә. «Туган җирем» темасы 11, «Татар дөньясы» 1 темадан тора. Һәр теманың үз күрсәткече бар. Алар һәр битнең өске өлешендә урнашкан.

## Темаларның төзелеше

Темалар бертөрле калыпка салынды. Алар икедән алып дүрткә кадәр булган дәресләрне үз эченә ала *(1 кушымтаны кара)*.

1) Аудиоязма белән эш. Дәрес темасына караган лексика белән танышу мөмкинлеге бирелә.

2) Геройлар ярдәмендә яңа темага якын килү, ФДБСка нигезләнеп, уку мәсьәләсен кую.

3) Кагыйдә.

4) Ныгыту өчен биремнәр. Шулар арасында мәҗбүри рәвештә халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бәйле эш тәкъдим ителә.

5) Парларда эш *(ике вариантта)*.

6) Куян күчтәнәчендә биреләчәк теориягә якын килү.

7) Куян күчтәнәче.

8) Куян күчтәнәчен ныгыту өчен биремнәр.

9) Теманы йомгаклау өчен күнегүләр, логик биремнәр, кызыклы эш төрләре.

10) Укучылар истә калдырырга тиешле сүзләр исемлеге. Алар белән эш дәрес дәвамында алып барылырга тиеш. Балаларны сүзлек белән эшләргә өйрәтү максатыннан, сүзләр тема ахырында алфавит тәртибендә бирелде.

Уку әсбабы ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләр) үз эченә ала. 1–5, 9–10 пунктлар һәр ике юнәлеш өчен дә тәкъдим ителә. 5 пунктта ❯ тамгасы белән тирәнтен өйрәнүчеләр өчен диалоглар бирелде. 6–8 пунктлар — тирәнтен өйрәнүчеләргә йөз тотып эшләнде. Әмма база өлешен өйрәнә торган укучылар белән эшләүче укытучылар, балаларның белем дәрәҗәләреннән, мөмкинлекләреннән чыгып, ❯ тамгасы астындагы биремнәрне дә эшли алалар. Ике юнәлешнең бер китапта бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләүгә дә этәргеч ясый.

«Туган җирем» темасындагы 11 тема шартлы рәвештә өч төркемгә берләштерелә: ел фасыллары һәм алар белән бәйле табигать күренешләре, яши торган урын (авыл, шәһәр), тирә-якны чолгап алган дөнья. Һәр төркемдә өйрәнелгән материалга «кабатлау» дәресе белән йомгак ясала.

Кабатлауда беренче бирем дәресләрдә тыңлаган аудиоязмаларның эчтәлегенә бәйле. Калган биремнәр өйрәнелгән лексик һәм грамматик материалны ныгыту өчен тәкъдим ителә. Кабатлауда да тирәнтен өйрәнүчеләр өчен махсус биремнәр ❯ тамгасы белән бирелә. Кабатлауда тыңлау өчен яңа текст һәм аның буенча күнегүләр дә урын алды.

## Уку әсбабындагы күнегү төрләре

*«Рольләргә бүлеп укы»* биреме ике материалны берләштерә. Беренчесе база өлешен өйрәнүчеләр өчен (11, 19, 27, 46, 52, 64, 74, 86, 103, 112, 127 битләр). Геройлар санына карап, репликалар төсле рамкаларда бирелде. Укучыга үз роленә караган сүзләрне күрергә күпкә уңайлы. Диалогның эчтәлеген чагылдырган рәсем балаларга ситуацияне яхшырак күзалларга булыша. Уку әсбабының ахыргы темаларында ике диалог бер форма эченә урнаштырылды (103, 112 битләр).

Икенче төр диалоглар тирәнтен өйрәнүчеләр өчен. Бу диалоглар, гадәттә, әзер килеш бирелми. Аларны тулыландырырга (12, 19, 47, 52, 87 битләр), репликаларны тиешле тәртиптә урнаштырырга (65 бит) һәм башка шундый эшләр башкарырга кирәк. Кайбер дәресләрдә авторларның әсәрләре диалог буларак тәкъдим ителә (27 бит).

*«Сүзләрне рәсемнәр белән тоташтыр»* биреме уку әсбабында еш очрый (12, 26, 51 һәм башка битләр). Бу эш төре укучыларда сүзләрне дөрес уку, дөрес язу күнекмәләре, игътибарлылык формалаштыра. Мондый биремнәр эш дәфтәрендә дә кабатлана.

*«Күчереп яз»*, *«Җөмләне язып бетер»* биремнәре укучыларда хатасыз, матур язу күнекмәләрен формалаштыру өчен тәкъдим ителә (12, 14, 22 һәм башка битләр).

Табышмак, ребус, логик биремнәр, башваткычлар да уку әсбабында еш урын алды. Бу эш төрләре, бердән, укучының фикерләү, уйлау сәләтен камилләштерергә булыша, икенчедән,

өйрәнелә торган лексик берәмлекләрне истә калдырырга мөмкинлек бирә (15, 23, 41, 48 һәм башка битләр).

*«Җөмләләр төзе»* дигән баш астындагы биремнәр (17, 25, 45, 63 һәм башка битләр) бирелгән җөмлә модельләре үрнәгендә, дөрес итеп җөмләләр төзергә, аларны сөйләмгә кертергә булыша.

*«Рәсемне кара. Анда булган сүзләрне билгелә»* кебек биремнәр (20, 36, 76 һәм башка битләр) шулай ук укучының сүз байлыгын арттыра, предмет атамаларын истә калдырырга, дөрес язу күнекмәләре формалаштырырга, игътибарлылыкны үстерергә ярдәм итә. Бу төр биремнәр дә эш дәфтәренә урнаштырылды.

Укучыларны әйләнә-тирәне күзәтергә, аны аңларга өйрәтү өчен, дәреслеккә *«Табигатьне күзәтүне дәвам ит»* (22 бит), *«Җиләк-җимеш, яшелчә күргәзмәсенә рәхим ит»* (38 бит), *«Рәсемнәрне кара. Тузганаклар нәрсәгә охшаган?»* (31 бит) кебек биремнәр, сораулар кертелде.

*«Сүзләрне (җөмләләрне) мәгънәләренә туры китереп тоташтыр»* дигән сүз+сүз (23, 139 битләр), рәсем+рәсем (77, 93 битләр), рәсем+җөмлә (24, 34, 144 битләр) модельләренә нигезләнеп эшләнгән биремнәрдә сүзләрне, җөмләләрне, рәсемнәрне парларга өйрәтү күздә тотыла. Мондый төр биремнәр шулай ук эш дәфтәрендә дә бар.

*«Реклама яса»* биремен башкару өчен, укучылар иң элек уку әсбабында бирелгән реклама үрнәге белән танышалар (37, 131 битләр). Аннан соң *Нәрсә ул реклама?* дигән сорауга җавап бирәләр. Укытучы укучыларга текстларында реклама ясала торган предметның яхшы сыйфатлары, башкалардан өстенлеге күрсәтелергә тиешлеген аңлата. Әлеге предметны мактарга кирәклеге әйтелә.

*«Шигырьне дәвам ит»*, *«Текстны дәвам ит»*, *«Җөмләләрне тулыландыр»* кебек биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмен камилләштерергә, сүз байлыгын арттырырга, сөйләмнәренә яңа лексик берәмлекләр кертергә булыша (39, 76, 107 һәм башка битләр).

Тест форматындагы биремнәр уку әсбабында карточкаларга урнаштырып (64, 89 бит), рәсемнәр белән (59, 140 һәм башка битләр) бирелә.

Дәреслектә текст белән эш үзәктә тора. Моның өчен укытучы аның авторына, текстның геройларына, эчтәлегенә игътибарны юнәлтергә тиеш. Кайбер текстлар белән эшләгәндә, укытучыга өстәмә мәгълүмат белән дә таныш булу кирәк. Мәсәлән, 32–33 битләрдә сыерчыклар турында текст укыйбыз. Укытучы аның белән эшләгәндә, сыерчыкларның җылы якта кышлаучы кош булуын, аларның көтү булып очуын, сыерчыкның үз җыры булмавын, аларның ишеткән авазларны кабатлауларын әйтеп китәргә тиеш.

Туры сөйләм янындагы тыныш билгеләре укучыларга таныш булмау сәбәпле, текстлар үзгәртелде, җөмләләр сәхнә әсәрләрендәге кебек, геройлар исеменнән әйтелде.

Дәреслектәге һәр рәсем уйлап урнаштырылды. Аларның һәрберсе белән өстәмә эшләү зарур.

Дәреслектә төрле төсләр белән эшләнгән таблицалар бар. Алар укучыларга җавапны тиз һәм уңайлы итеп бирергә булыша (29, 75, 95 һәм башка битләр).

Төрле темаларны өйрәнгәндә, укучылар балалар бакчасыннан ук таныш булган геройларны да очраталар. Инде күптән таныш геройлар турында өстәмә мәгълүмат алу балалар өчен тагын да мавыктыргыч. Әлеге геройлар икегә бүленә: әкият геройлары (төлке, Куян кызы, Гөлчәчәк һ.б.); Россия тарихында төрле яклап эз калдырган символ-геройлар (Мишка, барс малае Юни, Куян, Леопард, Ак аю һ.б.).

Дәреслекнең тагын бер үзенчәлеге — уеннар.

Аларны парлап та, төркемнәрдә дә, сыйныфның барлык укучыларын катнаштырып индивидуаль дә үткәреп була. Уеннарда текстлар, биремнәр, рәсемнәр чиратлаштырып бирелә. Бу уеннардагы эш төрләре укучыларны телгә караган материал белән генә таныштырып калмый. Анда укучылар төрле юнәлешкә караган кызыклы мәгълүмат туплый (сыерчыклар турында белә, юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерә һ.б.).

Дәреслектә өч уен урнаштырылды (32–33, 96–98, 135–137 битләр). Алар өчесе дә бер калыпка салынган.

Беренче уенның геройлары — Чык һәм Чик исемле ике сыерчык. Икенче уенныкы — авыл песие Наян. Өченче уенда төп герой — Биби исемле кыз.

Укучыларның бурычы — төрле биремнәрне хатасыз эшләп, әлеге геройларга тиешле урыннарга барып җитәргә булышу.

Геройларга уен дәвамында берничә пунктны узарга кирәк. Һәр пунктның үз биреме бар. Беренче уенда биремнәр уен эченә кертелсә, калган икесендә алар аерым биттә урнашкан.

***32–33 битләрдәге беренче уен***

Чик һәм Чыкка җылы яктан Туган илгә кайтырга кирәк. Моның өчен алар сыерчык көтүенә кушылырга тиешләр. Укытучы уенда катнашучыларга 1 нче биремне эшләргә куша. Балалар җөмләдәге хатаны табарга тиеш: *Көз көне сыерчыклар кайталар.* Җаваплар кабул ителә һәм нәтиҗә ясала.

Хатаны табып төзәткән укучылар «+» тамгасы куелган рәсемгә күчәләр. Күренгәнчә, анда геройлар сыерчык көтүенә кушыла алган. Хатаны төзәтә алмаган укучылар исә, «–» тамгасы торган рәсемгә күчә. Алар Чик белән Чыкка булыша алмадылар. Кошлар сыерчык көтүенә кушыла алмады, шуңа күрә бу балалар уеннан чыга.

Укучылар текстны укыйлар һәм алдагы этапка күчәләр. Икенче этапта балалар кечкенә текстны укып, анда артык җөмләне табарга тиешләр. Сыерчыкка туры килмәгән җөмләне таба алсалар, балалар Чик белән Чыкка диңгез аша очып үтәргә булышкан була. «+» тамгасы янындагы рәсемдә кошлар диңгезне очып үтеп, ял итеп утыралар. «–» тамгасы янындагы кошлар боек, чөнки алар утрауда калганнар. Биремне эшли алмаган укучылар уенны алга таба дәвам итми. Балалар сыерчыклар турындагы мәгълүматны укыйлар һәм алдагы биремгә күчәләр. Өченче биремдә уенчылар сорауларга җавап бирергә тиеш. Шул рәвешле, алар сыерчыкларга оя табарга булышалар. Өч сорауга да дөрес җавап биргән укучылар уенның җиңүчеләре була.

***96–98 битләрдәге икенче уен***

Песи малае Наянга шәһәрдәге циркка барып җитәргә булышырга кирәк. Ул өйдән чыгып китә һәм автобус тукталышына килә. Укытучы уенда катнашучыларга 98 биттәге 1 саны астындагы сорауга җавап бирергә куша: *Кызыл ут янса,*

*урам аша чыгарга ярыймы?* Җаваплар кабул ителә. Автобус тукталышы янында юл икегә аерыла. Берсенә «+» тамгасы, икенчесенә «–» тамгасы куелган. «+» тамгасы куелган юл песине дөрес сукмактан шәһәргә таба җибәрә, «–» исә песине урманга озата. Беренче сорауга дөрес җавап биргән укучылар, Наян белән бергә автобуска утырып, уенны дәвам итәләр. Сорауга җавап бирә алмаган укучылар песи белән бергә урманга китәләр, ягъни уеннан чыгалар.

Алга таба уенчылар икенче биремне эшләргә тиеш. Укытучы балаларга 98 биттәге икенче сорауга җавап бирергә куша: ***Елга, песи** сүзләрендә **е** хәрефе нинди авазлар белдерә?* Укучылар җавапларын язалар, аны укытучыга күрсәтәләр. Нәтиҗә ясала.

Ике сүздә дә аваз дөрес билгеләнергә тиеш. Берсе дөрес, икенчесе хаталы булса, җавап дөрес дип саналмый. Сорауга дөрес җавап биргән укучылар Наян белән бергә «+» тамгасы куелган шәһәр автовокзалына килеп җитәләр. Сорауга дөрес җавап бирмәгән балалар, Наян белән бергә «–» куелган күл буенда автобустан төшеп калалар, ягъни уеннан чыгалар.

Автовокзалдан алга таба циркка китү өчен, тагын бер биремне эшләргә кирәк. Укытучы уенда катнашучыларга 98 биттәге 3 саны астындагы биремнәрне эшләтә. Өч табышмакның җавабын әйтергә һәм җаваптагы сүзләрдә ***е, ю, я*** хәрефләре белдергән авазларны язарга кирәк. Бер генә хата булса да, җавап дөрес дип саналмый. Биремнәрне дөрес эшләгән укучылар, Наян белән «+» тамгасы куелган троллейбуска утырып, циркка китәләр. Хата җибәргән укучылар, Наянга ияреп, зоопаркка юл алалар, ягъни уеннан төшеп калалар.

Укытучы укучыларга соңгы сорауга җавап бирергә куша: *Троллейбус белән автобусның артыннан чыгарга ярыймы?* Җаваплар тыңлана һәм нәтиҗәләр ясала.

Бу сорауга да дөрес җавап биргән укучылар, Наян белән циркка килеп, тамаша карыйлар. Алар — уенның җиңүчеләре. Балалар сорауга җавап бирмәсә, Наянга ярдәм итә алмый. Алар троллейбустан төшеп калалар һәм, Наянны да ияртеп, авылга кайтып китәләр.

***135–137 битләрдәге өченче уен***

Биби авылда яши торган әбисенә кайнар кыстыбыйлар илтергә тели. Укучылар кызга урман аша чыгарга булышырга тиеш. Беренче булып Бибигә ач бүре очрый. Ул үзенең соравына җавап бирергә куша. Кыз сорауга дөрес җавап бирмәсә, бүре кыстыбыйларны ашаячак. Балалар бүренең соравына җавап бирә алсалар, кыз «+» тамгасы куелган юлдан алга таба китә. Ә инде уенда катнашучылар кызга булыша алмасалар (бер хата да булырга тиеш түгел), кыстыбыйларны бүре алып ашый, кәрзин бушый. Анда укучыларга җиңелгәнлекләрен күрсәтә торган «–» тамгасы гына кала. Ә Биби, елый-елый, өенә кайтып китә.

Алга таба Бибигә хәйләкәр төлке очрый. Төлке дә кызга шарт куя: биремне эшләсәң генә, алга таба китәсең. Уенчылар сүзләрне ике төркемгә аерып әйтергә (яки язарга) тиеш булалар. Төлкенең биремен хатасыз эшләгән укучылар Бибигә төлке яныннан исән-имин узып китәргә булышалар. Биремдә хата җибәрсәләр, кыстыбыйларны төлке тәмләп ашап бетерә. Кыз кире өенә кайтып китә. Бибигә булыша алмаган укучылар уеннан чыга.

Алга таба «+» тамгасы куелган юл буенча хәрәкәт итеп, Биби аю янына килеп җитә. Аюга да кәрзиндәге кыстыбыйлар бик тәмле күренә. Ул да кызга үзенең сорауларын бирә. Уенда катнашучылар ике сорауга да төгәл җавап бирергә тиеш булалар. Дөрес җаваплары өчен укытучы аларны җиңүче дип игълан итә. Уенчылар кызга әбисе янына килеп җитәргә ярдәм итәләр. Биби әбисе белән кайнар кыстыбыйлар ашап, тәмләп чәй эчә. Бибигә булыша алмаган балалар уенны соңгы этапта ташлап китәргә мәҗбүр була. Алар ярдәме белән аю кыстыбыйларны ашап бетерә. Биби, әбисе янына барып җитә алмыйча, кире кайтып китә.

## ТЕМАТИК ПЛАН*

| № | Дәреснең темасы | | Сәгать саны | Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр | Укучыларның эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | Лексик тема | Грамматик тема | | | |
| **Туган җирем** | | | | | |
| 1. | Бу кайсы вакыт? | Сөйләм. Телдән сөйләм. Язма сөйләм. | 2 | Сөйләмнең нәрсә икәнен аңлау. Аның телдән һәм язма төрләрен аера белү.<br><br>Җөмләләрне дөрес интонация белән уку.<br><br>*Терминнар:* сөйләм, телдән сөйләм, язма сөйләм, интонация.<br><br>*Сүзлек эше:* ел фасылы, сыерчык, агач төбе, йомшарта, тамыр.<br><br>*Дәреслек:* 8–12, 15 битләр. 8–15 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 4–6 битләр. | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстны тыңлап аңлау, уку, сөйләү, дөрес язу. Рәсемнәр ярдәмендә сөйләм төзү. Сөйләм төрләрен тану. Дөрес интонация белән уку, сөйләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | *Интонация.* | 2 | | |

* Кара хәрефләр белән бирелгән материал ике юнәлешкә дә, зәңгәр төс белән бирелгәне тирәнтен өйрәнүчеләргә генә карый.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Кар бөртеге | *Җөмлә.* | 3 | Җөмлә төзү күнекмәләре булдыру. Сүз белән җөмләнең аермасын белү. Сүзләрдән җөмлә төзелүе, җөмләдә беренче сүзнең баш хәрефтән язылуы, җөмлә ахырында нокта куелуы турында белү.<br><br>Сорау җөмләне башка җөмләләрдән аеру. Аны дөрес интонация белән әйтү.<br><br>Табышмак ярдәмендә фикерләү сәләтен үстерү.<br><br>*Терминнар:* җөмлә, сорауны белдерә торган сүзләр, *-мы/-ме.*<br><br>*Сүзлек эше:* тәңкә кар, саф һава, кар бөртеге, эре кар бөртеге.<br><br>*Дәреслек:* 16–20, 22–23 битләр. 16–23 битләр. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Текстны тыңлап аңлау, уку, сөйләү, дөрес язу. Диалогта катнашу.<br><br>Дәреслектәге рәсемнәр белән эшләү.<br><br>Сорауны белдергән сүзләр, *-мы/-ме* кисәкчәсен дөрес кулланып, җөмләләр төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчән-легеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | *Җөмләдә сорауны белдерү.* | 1 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *Эш дәфтәре:* 7–11 битләр. | |
| 3. | Яз килә, яз көлә | *Текст.* | 2 | Текстның нәрсә икәнен аңлау. Аерым җөмләләрдән текстны аеру, текст төзү күнекмәләре формалаштыру.<br><br>Җөмләдә сүз тәртибе белән танышу.<br><br>*Терминнар:* җөмлә, текст, сүз тәртибе.<br><br>*Сүзлек эше:* кара карга, тукран, көтү, охшаган, тузганак, утрау, сайрый.<br><br>*Дәреслек:* 24–29, 31–33 битләр. 24–33 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 12–15 битләр. | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстны тыңлап аңлау, дөрес уку, сөйләү, язу. Уен ярдәмендә лексик берәмлекләрне сөйләмгә кертү, сөйләм күнекмәләре булдыру.<br><br>**Нишли?** соравына җавап биргән сүзне ахырга куеп җөмлә төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | ***Нишли?*** *соравына җавап биргән сүзнең җөмләдәге урыны.* | 1 | | |
| 4. | Җәйнең байлыгы — кояш, | *Хикәя җөмлә. Тойгылы җөмлә.* | 2 | Җөмлә төрләрен, алар ахырында куела торган тыныш билгеләрен белү. | Уку бурычын дөрес билгеләү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Көзнең байлыгы — уңыш | *Сорау җөмлә.* | | Җөмләнең бер генә сүздән дә тора алуын аңлау.<br><br>*Терминнар:*<br>Хикәя җөмлә.<br>Тойгылы җөмлә.<br>Сорау җөмлә.<br><br>*Сүзлек эше:*<br>күргәзмә, файдалы, ярканат, табигать.<br><br>*Дәреслек:*<br>34–39, 41–42 битләр.<br>34–42 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>16–20 битләр. | Хикәя, тойгылы һәм сорау җөмләләр төзү, аларны тану. Хикәя, тойгылы һәм сорау җөмләләр ахырына тиешле тыныш билгесен кую.<br><br>Рәсем белән җөмлә арасындагы уртак мәгънәне табу. Әкияттән өзек, рәсемнәр белән эшләү. Башваткыч чишү. Ел фасылларын дөрес санау, яраткан ел фасылын әйтү, ни өчен яратуын аңлату.<br><br>Сүз һәм бер генә сүздән торган җөмләне бутамау. Реклама тексты яза белү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | *Бер сүздән торган җөмлә.* | 1 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Аяз көнне бар, болыт-лы көн-не юк | *Иҗек.*<br><br>*Сүзне юлдан-юлга күчерү.* | 2<br><br>1 | Сүзләрнең иҗекләрдән торуын, иң кечкенә иҗекнең бер генә сузык аваздан торуын белү.<br><br>Иҗекләргә карап, сүзләрне юлдан-юлга күчерү.<br><br>*Терминнар:* иҗек, хәреф, сызыкча.<br><br>*Сүзлек эше:* аяз, болытлы, яшен, яшенле яңгыр, кызу, һава торышы.<br><br>*Дәреслек:* 43–46, 48–49 битләр. 43–49 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 21–22 битләр. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Һава торышы турында сөйли белү.<br><br>Сүзләрне иҗекләргә аерырга, аларны санарга өйрәнү.<br><br>Телдән сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. Табышмакның җавабын табу, иҗекләрдән дөрес итеп сүзләр төзү.<br><br>Сүзләрне дөрес итеп юлдан-юлга күчерү. Диалог төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеең-нең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 6. | Ләй-сән — рәхмәт яңгыры | *Басым.*<br><br>*Басымлы иҗек.* | 2<br><br>1 | Сүзләрдә көчлерәк әйтелгән иҗекнең басым дип аталуын белү. Басым тамгасы белән танышу. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Сүзләрне басым куеп уку. Диалогларда катнашу. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татар телендә басымның, гадәттә, соңгы иҗеккә төшүен, ә сорауны белдергән сүзләрдә басымның беренче иҗеккә төшүен хәтердә калдыру.<br><br>Сүздә басым төшкән иҗекнең басымлы иҗек дип аталуын белү.<br><br>*Терминнар:* басым, басымлы иҗек.<br><br>*Сүзлек эше:* бәс, кызгылт-сары, шәмәхә, чык, табигать күренешләре.<br><br>*Дәреслек:* 50–53, 55 битләр. 50–55 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 23–25 битләр. | Тыңлаган текст белән эшләү, сүзләр һәм рәсемнәр арасындагы мәгънәне табу.<br><br>Диалогны тулыландыру, табышмакның җавабын табу. Табигать күренешләре турында әңгәмә кору, җөмләләр төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 7. | Кабат-лау | | 1 | Яңа текст тыңлап, аның белән эшләү. | Дәресләрдә тыңлаган, укыган текстларның эчтәлеге белән эшләү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Дөрес уку, сөйләү, язу күнекмәләре булдыру.<br>*Дәреслек:* 56–59 битләр.<br>56–60 битләр.<br>*Эш дәфтәре:* 26–30 битләр. | Өйрәнелгән грамматик материалны кабатлау.<br>Сорауларга җавап бирү. |
| 8. | Туган илем — туган өем | *Сузык авазлар.* | 3 | Авазларның язуда хәрефләр белән күрсәтелүен, авазларның квадрат җәя эчендә алынуын, авазларның сузык һәм тартыкларга бүленүен белү. Сузык авазларның калын һәм нечкә төрләре белән танышу.<br>***О** һәм **ө*** сузык авазларының сүзнең беренче иҗегендә генә язылуын аңлау.<br>Терминнар: аваз, хәреф, сузык аваз, тартык аваз, калын сузык аваз, нечкә сузык аваз, ***о*** хәрефе, ***ө*** хәрефе, [о] авазы, | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сүздә сузык авазлар һәм иҗекләр саны тигез булуны аңлау. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны таный белү. Бирелгән җөмлә модельләре ярдәмендә җөмләләр төзү.<br>Сәнгатьле итеп уку, сөйләү, дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү. *Туган шәһәр, туган авыл, туган ил* төшенчәләре белән эшләү.<br>Икенче иҗектә дә [о], [ө] авазлары |
| | | ***О** һәм **ө** хәреф-ләренең сүздәге урыны.* | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | [ө] авазы.<br><br>*Сүзлек эше:* борынгы, урнашкан, Туган ил, Россия.<br><br>*Дәреслек:* 61–64, 67–70 битләр.<br>61–70 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 31–33 битләр. | ишетелгән сүзләрне дөрес язу.<br>Мәкальләрне уку, аларның мәгънәләрен аңлату.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 9. | Бай тарихлы башкала | *Тартык авазлар.* | 3 | Тартык авазларны сузык авазлардан аера белү. Яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны танырга өйрәнү. Татар теленең үзенчәлекле авазларын белү.<br><br>Яңгырау һәм саңгырау тартыкларның парлашуын өйрәнү. Парлы һәм парсыз тартык авазларны аера алу.<br><br>*Терминнар:* Тартык аваз, яңгырау тартык аваз, саңгырау | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Җөмлә модельләре, табышмак, диалоглар белән эшләү.<br><br>Мәскәү шәһәре, аның тарихы турында кыскача мәгълүмат туплау.<br><br>Универсиада, җәйге һәм кышкы олимпиада символлары белән танышу.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү. |
| | | *Парлы тартык авазлар.* | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тартык аваз,<br>парлы тартык авазлар, парсыз тартык авазлар.<br><br>*Сүзлек эше:*<br>мәйдан, тарих, тарихи,<br>универсиада, олимпиада.<br><br>*Дәреслек:* 71–77, 80–81 битләр.<br>71–81 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>34–41 битләр. | Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 10. | Шәһәр — авыл арасы | ***Е, ю, я*** *хәрефләре.*<br><br>*Сүздә* ***ъ*** *һәм* ***ь*** *язылу.* | 2<br><br>2 | ***Е, ю, я*** хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдерүен аңлау. ***е*** хәрефенең тартыклардан соң [э] дип укылуы белән танышу.<br>***Е, ю, я*** хәрефләре алдыннан калынлык һәм нечкәлек билгеләренең язылу үзенчәлекләре турында мәгълүмат алу.<br><br>*Терминнар:*<br>хәреф,<br>сузык аваз. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>***Е*** хәрефенең [йы], [йэ], [э] авазларын, ***ю*** хәрефенең [йу],[йү] авазларын, ***я*** хәрефенең [йа], [йә] авазларын белдерүен истә калдыру.<br><br>Шәһәр белән авылны чагыштырып сөйләү. Шәһәрнең истәлекле урыннары турында әңгәмәдә катнашу. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *Сүзлек эше:* иркә, киң, манара.<br><br>*Дәреслек:* 82–89, 92–98 битләр. 82–98 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 42–45 битләр. | Уен ярдәмендә лексик һәм грамматик материалны ныгыту.<br><br>Казан шәһәре турында сөйләү.<br><br>Нечкә иҗектән соң ***е, ю, я*** хәрефләре килсә, нечкәлек билгесе ***(ь)*** язылу, калын иҗектән соң ***е, ю, я*** хәрефләре килсә, калынлык билгесе ***(ъ)*** язылу очракларын белү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 11. | Кабатлау | | 1 | Яңа текст тыңлап, аның белән эшләү.<br><br>Дөрес уку, сөйләү, язу күнекмәләре булдыру.<br><br>*Дәреслек:* 99–101 битләр. 99–101 битләр. | Дәресләрдә тыңлаган, укыган текстларның эчтәлеге белән эшләү. Өйрәнелгән грамматик материалны кабатлау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *Эш дәфтәре:* 46–48 битләр. | Сорауларга җавап бирү. Рәсемнәр белән эшләү. |
| 12. | Минем тирә-ягым | *Баш хәреф-тән языла торган сүзләр.* | 2 | Татар телендә баш хәрефтән язылa торган сүзләрне белү.<br><br>Сүзләрнең исемлеген төзү өчен, аларны алфавит тәртибендә язу.<br><br>*Терминнар:* баш хәреф, исемлек, алфавит.<br><br>*Сүзлек эше:* күл, сәяхәт, энже чәчәк.<br><br>*Дәреслек:* 102–106, 108 битләр. 102–108 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:* 49–51 битләр. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Кеше исеме, фамилиясе, хайван кушаматы, ил, район, шәһәр, авыл, урам, елга, күл, тау исемнәрен баш хәрефтән язарга өйрәнү.<br><br>Россия шәһәрләре атамаларын белү. Текст, диалог төзү.<br><br>Кеше, елга, тау, шәһәр, авылларның исемлеген төзү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | *Сүзләрне алфавит тәрти-бендә язу.* | 1 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Тиен, керпе, бүре, куян Йөриләр бер сукмактан | *Сүзгә кушымча ялгану.*<br><br>*Сүзгә күплек сан кушымчасы ялгану.* | 2<br><br>1 | Сүзләргә дөрес итеп кушымчалар ялгау. Һәр кушымчаның ике варианты булуы (калын һәм нечкә) турында мәгълүмат алу. Калын сүзгә калын кушымча, нечкә сүзгә нечкә кушымча ялгау күнекмәсе формалаштыру.<br><br>Татар телендә күплек санны белдерү өчен, сүзләргә *-лар/-ләр* кушымчасы ялгану, *м,н,ң* хәрефләренә тәмамланган сүзләргә *-нар/-нәр* кушымчасы ялгануны истә калдыру.<br><br>*Терминнар:* кушымча, берлек сан, күплек сан.<br><br>*Сүзлек эше:* болан, көртлек, поши, томшык, шапшак, кәрзин. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Калын, нечкә сүзне аеру. Калын һәм нечкә сүзләргә тиешле кушымчаларны ялгап язу.<br><br>Текстны тыңлау, аның эчтәлеге белән эшләү. Урман җәнлекләре турында җөмләләр төзү, әңгәмә кору.<br><br>*М,н,ң* хрефләренә тәмамланган сүзләргә дөрес итеп күплек кушымчасы ялгап язу. Сүзләрне күплектә кулланырга өйрәнү.<br><br>Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *Дәреслек:*<br>109–116,<br>118 битләр.<br>109–118 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>52–57 битләр. | |
| 14. | Кабат-<br>лау | | 1 | Яңа текст тыңлап, аның белән эшләү.<br><br>Дөрес уку, сөйләү, язу күнекмәләре булдыру.<br><br>*Дәреслек:*<br>119–122 битләр.<br>119–122 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>58–60 битләр. | Дәресләрдә тыңлаган, укыган текстларның эчтәлеге белән эшләү. Өйрәнелгән грамматик материалны кабатлау.<br><br>Табышмак-<br>ларның җавабын табу. |
| **Татар дөньясы** | | | | | |
| 15. | Телне йотар-<br>лык тәмле | *Кем?, нәрсә? сораула-<br>рына җавап биргән сүзләр* | 3 | Татар телендә кем?, нәрсә? сорауларын дөрес куллану күнекмәсе булдыру.<br><br>Җанлы һәм җансыз предметларны аеру. | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br><br>Татар телендә кешеләргә карата кем? соравын куллану. Хайваннарга, кошларга, балыкларга нәрсә? соравын кую. |
| | | *Җанлы һәм җансыз предмет-<br>лар.* | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *Терминнар:*<br>хәреф,<br>сузык аваз.<br><br>*Сүзлек эше:*<br>бәлеш, коймак,<br>гөбәдия, чәкчәк,<br>кыстыбый,<br>кыстыбургер,<br>татар милли<br>ашлары,<br>өрек, йөзем,<br>тартма, кучтәнәч.<br><br>*Дәреслек:*<br>124–130,<br>134–137 битләр.<br>124–137 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>61–64 битләр. | Татар милли<br>ашлары, яраткан<br>ризык турында<br>текст, диалог<br>төзеп сөйләү.<br>Дөрес уку, телдән<br>сөйләү, язу.<br>Уен, табышмак,<br>ребус чишү<br>аша лексик<br>һәм грамматик<br>күнекмәләрне<br>ныгыту.<br>Реклама тексты<br>язу.<br><br>Җанлы һәм<br>җансыз<br>предметларны<br>белү, аларга<br>карата дөрес<br>сорауны куллану.<br><br>Дәреслекнең<br>сүзлекчәсе белән<br>эшләү.<br><br>Үз<br>эшчәнлегеңнең<br>нәтиҗәсенә бәя<br>бирү. |
| 16. | Кабат-<br>лау | | 2/1 | Яңа текст тыңлап,<br>аның белән<br>эшләү. | Дәресләрдә<br>тыңлаган, укыган<br>текстларның<br>эчтәлеге белән<br>эшләү. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Дөрес уку, сөйләү, язу күнекмәләре булдыру.<br><br>*Дәреслек:*<br>138–141 битләр.<br>138–142 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>65–67 битләр. | Өйрәнелгән грамматик материалны кабатлау.<br><br>Мәкальләрне укып, мәгънәсенә төшенү. Рәсемнәр белән эшләү. |
| 17. | Гомуми кабат-лау | | 2 | Беренче сыйныфта өйрәнгән материалны кабатлау.<br><br>Дөрес уку, сөйләү, язу күнекмәләре булдыру.<br><br>*Дәреслек:*<br>143–145 битләр.<br>143–145 битләр.<br><br>*Эш дәфтәре:*<br>68–70 битләр. | Текстны рольләргә бүлеп уку. Аңа исем сайлау. Төшеп калган хәрефләрне куеп,җөмләләрне күчереп язу. Җөмләләрне тулыландырып күчереп язу. |
| | | | 35/<br>53 | | |

# ДӘРЕС ПЛАННАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Тема: Бу кайсы вакыт?**
**2 / 4* сәгать**

## 1 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** укучыларны быелгы уку елына куелган максат һәм бурычлар, дәреслек һәм аның үзенчәлекләре, шартлы билгеләр, ярдәмче геройлар белән (Байгыш, Нур һәм Бытбылдык) таныштыру; елның дүрт фасылын искә төшерү; *сөйләм* төшенчәсе, телдән сөйләм, язма сөйләм турында мәгълүмат бирү һәм ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Туган тел (татар теле) дәресләре турында әңгәмә.

2) «Бүләк кемгә?» экиятен тыңлау.

3) «Бүләк кемгә?» экиятенең эчтәлеге белән эшләү (сораулар һәм җаваплар).

4) Экият эчтәлеге ярдәмендә сөйләм төрләрен ачыклау.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Ел фасылларының төп билгеләре.

2) Сөйләм һәм аның төрләре.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Ел фасылына багышланган рәсемнәр белән эшләү (8 бит).

2) Нур ярдәме белән сөйләм һәм аның төрләре турында әңгәмә кору (9 бит).

---

* База өлешен өйрәнүчеләр белән эшләгәндә теманы өйрәнүгә 2 сәгать бирелә. Бу дәресләрнең план үрнәкләре кара хәрефләр белән бирелде. Тирәнтен өйрәнүчеләр белән эшләгәндә темага 4 сәгать бирелә. Алдагы 2 дәрестән тыш зәңгәр хәрефләр белән бирелгән 2 дәреснең план үрнәге дә өстәлә.

3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

4) Ярдәмче геройлар белән яраткан ел фасыллары турында сөйләшү (10 бит).

5) Эш дәфтәре белән эшләү, 3 бит (дөрес язу күнекмәләрен, алфавит тәртибен, хәрефләрнең дөрес язылышын искә төшерү).

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 2 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** яраткан ел фасылы турында сөйләшүне дәвам итү; телдән һәм язма сөйләмнең аермасын төшендерү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: сөйләмиятнең төрләрен билгеләү (ишетеп аңлау, сөйләү, язу, уку).

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Кыш һәм язның беренче билгеләре.

2) Сөйләмиятнең төрләре.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) «Куян кызы» экиятенә караган рәсем белән эшләү (ел фасылы буларак кыш турында сөйләшү, сөйләм төрләрен искә төшерү) (10 бит).

2) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

3) Парларда эш (11 бит).

4) Күнегүләр эшләү (12, 15 битләр).
5) Эш дәфтәре белән эшләү (4–6 битләр)
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** ел фасыллары турында сөйләшүне дәвам итү; интонация турында мәгълүмат бирү.
**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).
**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**
***1. Дәресне оештыру.***
Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.
***2. Актуальләштерү.***
1) Өй эшен тикшерү.
2) 13 биттәге 3 күнегү ярдәмендә интонация төшенгәсен ачыклау.
***3. Уку мәсьәләсе кую.***
1) Ел фасыллары. Кышкы уеннар.
2) Дөрес интонация белән җөмләләр төзү.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**
1) Ярдәмче геройлар белән әңгәмә (13 бит).
2) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
3) Күнегүләр эшләү (13 бит).
4) Парларда эш (12 бит)
5) Эш дәфтәре белән эшләү (3 күнегү, 4 бит)
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

### 4 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** язгы эшләр, бакча турында сөйләшү; текстларны дөрес интонация белән уку.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Табигать турында сөйләшү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Әйләнә-тирә дөнья.
2) Текстны дөрес интонация белән уку.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
2) Текст белән эш (5 күнегү, 14 бит).
3) Күнегүләр эшләү (6–7 күнегүләр, 14 бит).
4) Эш дәфтәре белән эшләү (4–5 күнегүләр, 5 бит)
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## Тема: Кар бөртеге

**3/ 4 сәгать**

### 1 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** кар бөртекләре мисалында кышкы табигатьне күзәтергә өйрәтү; җөмлә турында мәгълүмат бирү; укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу дәресе.
**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) «Куян кызы» әкиятен тыңлау.
3) «Куян кызы» әкиятенең эчтәлеге белән эшләү (сораулар һәм җаваплар).
4) Әңгәмә.

Кышкы табигать, кар бөртекләре төре турында сөйләшү ярдәмендә җөмләгә билгеләмә бирү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Кышкы табигатьнең үзенчәлекләре.
2) Җөмлә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Кар бөртекләренә багышланган рәсем белән эшләү (16 бит).
2) Геройлар ярдәмендә кар бөртекләренең төрләре турында әңгәмә оештыру (16 бит).
3) Модельләргә карап, җөмләләр төзергә өйрәнү (17 бит).
4) Рәсем ярдәмендә геройлар белән берлектә сүз белән җөмләне аерырга өйрәнү.
5) Эш дәфтәре белән эшләү (1–3 күнегүләр, 7–8 бит).
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 2 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** укучыларны әкият геройларының уй-хисләренә, эш-гамәлләренә тиешле, дөрес бәя бирә белергә, мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле, ярдәмчел булырга өйрәтү; җөмлә турында төшенчә бирүне дәвам итү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Ярдәмче геройлар белән җөмләнең сүзләрдән торуын ачыклау.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Кышкы шөгыльләр.
2) Сүз һәм җөмлә.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Л. Толстойның «Төлке, Куян һәм әтәч» әкиятенә карата 18 биттәге рәсем һәм сораулар белән эш (әкият геройлары, аларның эш-гамәлләре турында сөйләшү, җөмләнең сүзләрдән торуын искә төшерү).

2) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

3) Парларда эш (Рольләргә бүлеп уку – 19 бит / Диалогны тулыландыр — 19 бит).

4) Күнегүләр эшләү (20 бит).

5) Эш дәфтәре белән эшләү (5 күнегү, 9 бит; 4 күнегү, 8 бит).

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** кышкы табигатьне күзәтүне дәвам итү; сорауны белдергән сүзләр, *-мы/-ме* кисәкчәсен дөрес кулланып, җөмләләр төзү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу дәресе.

**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә.

Байгыш ярдәмендә сорауны белдергән сүзләрне, сорау кисәкчәләрен билгеләү.

***3. Уку мәсьәләсе кую***

1) Кышкы һава.

2) Татар телендә сорауны белдерү чаралары.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Куян күчтәнәче белән танышу. Нәтиҗәләр ясау.

2) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

3) Күнегүләр эшләү (3 күнегү, 21 бит).

4) Эш дәфтәре белән эшләү (6–8 күнегүләр, 10 бит).

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 4 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерү; җөмләдән *нишли?* соравына җавап биргән сүзләрне табарга өйрәтү; бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).
**Җиһазлау:** электрон дәреслек, аудиоязмалар (диск).

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**
***1. Дәресне оештыру.***
Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.
***2. Актуальләштерү.***
1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә.
Җөмләнең *нишли?* соравына тәмамлануы турында сөйләшү.
***3. Уку мәсьәләсе кую***
1) Табигатьне күзәтү.
2) Җөмләдән *нишли?* соравына җавап биргән сүзләрне табу.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**
